РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
МЭР ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ МЭРЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2 август, 2024 ел** **№ 7**

Җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән куллану төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Кукмара поселок Советының 2023 елның 25 декабрендәге 28 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә, Кукмара шәһәре Советының 2020 елның 17 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә таянып карар бирәм:

1. 2024 елның 2 сентябрендә 17 сәгать 00 минутта Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 15 йорт адресында урнашкан Кукмара шәһәре Башкарма комитеты бинасында (1 нче каттагы 107 нче кабинет) түбәндәге адреста урнашкан җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздырырга:

- Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре шәһәр җирлеге, Кукмара шәһәре, Эшчеләр тыкрыгы ур., 77А җир кишәрлеге, мәйданы 67 кв.м, кадастр номеры 16:23:260108:586 «Автотранспортны саклау» төренә.

2. Әлеге карарны Кукмара шәһәре территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» челтәрендә Кукмара муниципаль районы рәсми сайтында http://kukmor.tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кукмара шәһәре Башкарма комитеты каршындагы җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә йөкләргә.

**Кукмара шәһәре мэры** **С.Д. Димитриев**